| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 03.07.2015 г. Казань № 10-13/кс

***2015 елга «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖе өчен техник суга тариф билгеләү турында***

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖе өчен техник суга тарифны әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф 2015 елның 1 августыннан 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы айга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт комитеты
карарына кушымта
03.07.2015 № 10-13/кс

Салкын су белән тәэмин итүче һәм су бүлүне башкаручы
«Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖе өчен
2015 елга эчәргә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүче һәм (яисә) су бүлүне башкаручы оешмалар, муниципаль берәмлекләр атамасы | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы) сум/куб. | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы) сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Менделеевск муниципаль районы | | |
| 1 | «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖе | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 35,60 | 23,59 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | 30,17 | 19,99 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге